СОВЕТ
Кучуковского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлеге
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2019 Түбән Көчек авылы № 50-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 29-2 номерлы "Җир салымы турында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм "Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм "Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советы к а р а р б и р д е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 29-2 номерлы "Җир салымы турында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче бүлекнең 3 абзацында "(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)" сүзләрен өстәргә;

1.2. 5нче бүлекнең 1 абзацында " - физик затлар" сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 6нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү узган салым чорыннан соң килүче икенче айның беренче, икенче һәм өченче кварталларыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенә туры килә торган ¼ салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.».

2. Карарның 1.3. пункты гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарның 1.1., 1.2. пунктларының гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк һәм тиешле салым буенча чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге советының Финанс-бюджет, социаль Законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе Р.Ә.НУРМӨХӘМӘТОВ

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Кучуковского сельского поселения
Көчек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ